26 апрельдә бар татар доньясы Туган тел конен бәйрәм итә. Әлеге бәйрәм халкыбызнын боек шагыйре Габдулла Тукайнын туган коне унаеннан 1992 елнын 22 февралендә игълан ителгән. Үз телен, динен, милләтен ихтирам иткән, татарлыгы белән горурланган һәркем әлеге датаны яхшы белә. Татар доньясына гына түгел, башка милләт вәкилләренә дә Габдулла Тукай, анын шигърияте яхшы таныш.

Һәр милләт күп гасырлар дәвамында буыннан-буынга тапшырылып килгән, бәяләп бетергесез хәзинә булып саналган милли гореф-гадәтләргә, йолаларга, туган телгә бәйле асылын һәм тарихын саклау хокукына ия. Мордовия жирендә күп гасырлар дәвамында төрле милләт вәкилләре дус һәм тату гомер итә. Уртак максатыбыз - төрле телләрнен үзара ярашып яшәвенә ирешү. Сабыйлар да, олкәннәр дә һәрвакыт туган телебезне яратып, анын янгырашын, тәмен тоеп яшәсеннәр иде. Бүгенге глобальләшү чорында без күпмилләтле ватаныбызда телебезне саклауга аеруча игътибарлы булырга тиешбез.

Туган телем!.. Синен матурлыгын, синен газизлеген, синен кирәклеген турында кемнәр генә нинди матур сүзләр әйтмәгән! Соекле Тукаебызнын «Туган тел»е татарларнын гимнына әверелде. Жиде миллионлы татар жырлый аны: «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнен теле! Доньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы».

Республикада халыкларынын мәдә-ниятен, гореф-гадәтләрен, милли йолаларын саклау һәм үзара баету очен максатчан эш алып барыла. Яшь буын туган телне ойрәнсен, аны тормышта куллансын очен хакимият һәм гражданлык институтлары бергәләп эшлибез. Мордовия татар мәктәпләребездә туган татар телебезне ойрәнәбез, татар мәдәнияты жимеше булган жырларыбызны жыр-лыйбыз, шигырьләрне сәнгатьле яттан сойлибез, гореф-гадәтләребезне саклыйбыз. Илебезнен демократик үсеше һәм жәмгыятьтә тотырыклылык булдыру очен бу аеруча моһим.

Хормәтле дуслар! Һәрберебез очен Туган тел коне тынычлык, дуслык, бердәмлек бәйрәме булсын! Чын күнелдән сезгә нык сәламәтлек, бәхет һәм унышлар телибез!